| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ГОРОДИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ГОРОДИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Городище авылы

24 апрель 2025 ел № 53/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Городище авыл җирлегендә Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 17.11.2006 № 11/4 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлегендә Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенең 6 статьясына, түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Оператив-эзләү эшчәнлеген яисә Россия Федерациясе иминлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга, күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларына эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, федераль башкарма хакимиятнең иминлек тәэмин итү өлкәсендәге органының, тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, дәүләт саклау өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының иминлеген тәэмин итү максатларында мөрәҗәгатьләрне электрон документ рәвешендә җибәрүнең һәм мөрәҗәгатьләргә, мөрәҗәгатьләргә җаваплар җибәрүнең махсус тәртибе билгеләнергә мөмкин.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Городище авыл җирлеге башлыгы урынбасары
Чүпрәле муниципаль районы
Татарстан Республикасы Р.Ф. Алимов